ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 гыйнвар 2024 ел № 04

Башкарма комитетның «Балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмалар тарафыннан аларга беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү өчен комиссия төзү, критерийларны, шулай ук эксперт бәяләве формаларын раслау турында» 2023 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 635-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 24 июлендәге 1194 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмалар тарафыннан аларга беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү өчен комиссия төзү, критерийларны, шулай ук эксперт бәяләве формаларын раслау турында» 2023 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү яисә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү буенча комиссия төзү турында»;

2) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 2, 4 пунктлары, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым чаралар турында»

2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Законының 2, 3 өлешләре, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә»;

3) 1 пунктта «балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмалар тарафыннан аларга беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия» сүзләрен «муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү яисә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү буенча комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Комиссия турында нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча.»;

5) 2 пунктның 3 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

6) 1 нче кушымтада «балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмалар тарафыннан аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында» сүзләрен «муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү яисә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында» сүзләренә алмаштырырга;

7) 2 нче кушымтаны, әлеге карарга кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә;

8) 3-5 нче кушымталар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 9 гыйнварындагы
4 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2023 елның 9 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү яисә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү буенча комиссия турында
нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Комиссия тарафыннан муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү яисә мондый оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

1) эксперт бәяләмәсе – муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында яисә оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү;

2) оешма – балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма;

3) балалар өчен социаль инфраструктура объекты – җир участогы, бина, төзелмә, корылма, җиһаз һәм аның барлыкка килүе, аны аерып яки сатып алу балаларның белеме, үсеше, ялы һәм аларны сәламәтләндерү, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм аларда авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән һәм муниципаль мөлкәт булып торган башка мөлкәт;

4) балалар өчен социаль инфраструктура объектыннан файдалану – муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләнешен үзгәртү яки аны бетерү, оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү яисә муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү;

5) комиссия – муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында яисә

оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия.

3. Эксперт бәяләвен, оешманың Башкарма комитетка мөрәҗәгате нигезендә яки Башкарма комитет инициативасы буенча тармак идарәсе башлыгы исеменнән, комиссия гамәлгә ашыра.

4. Комиссияне комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыручы рәис җитәкли, мәсьәләләр буенча коллегиаль фикер алышуны тәэмин итә, бурычларны бүлә һәм комиссия әгъзаларына йөкләмә бирә. Комиссия әгъзаларының минималь саны, комиссия рәисен исәпкә алып, җиде кеше тәшкил итә. Рәис булмаганда аның функциясен комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссия утырышларны кирәк булган саен үткәрә.

Комиссия утырышы, кимендә аның составының яртысы катнашкан очракта, тулы хокуклы дип санала.

Нигезле һәм объектив карар кабул итү максатларында, комиссия утырышларында катнашу өчен, комиссия әгъзалары сыйфатында башка кызыксынган дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкилләре чакырылырга мөмкин. Комиссия әгъзалары комиссия эшендә ирекле һәм түләүсез нигездә катнаша.

5. Комиссия түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән критерийлар нигезендә, муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрә;

2) муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү турында бәяләмә әзерли;

3) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийлар нигезендә, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрә;

4) балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү турында бәяләмә әзерли.

6. Әлеге Нигезләмәнең 8 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән һәм тапшырылган документлар нигезендә, комиссия муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү яисә, муниципаль белем бирү оешмасыннан тыш, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрә.

7. Үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне хәл иткәндә үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкару өчен, комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) карала торган мәсьәләләр буенча карар кабул итү өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны соратып алырга һәм аларны тапшыру срокларын билгеләргә;

2) эшче төркемнәр төзергә.

8. Балалар өчен социаль инфраструктура объектыннан файдалану турында карар кабул итү өчен, тармак идарәсе комиссиягә үз инициативасы буенча яки оешма мөрәҗәгате нигезендә эксперт бәяләвен үткәрү турында язмача гариза җибәрә, ул түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) балалар өчен социаль инфраструктура объектының тулы исеме, аның урнашу урынының адресы, гариза биргән көнгә торышы буенча балалар өчен социаль инфраструктура объектының билгеләнешен һәм фактта эксплуатацияләүне күрсәтү (шул исәптән оператив идарә хокукында беркетү, аренда, түләүсез файдалану шартнамәсе буенча вакытлыча файдалануга тапшыру турындагы мәгълүматлар);

2) оешмага беркетелгән балалар өчен социаль инфраструктура объектыннан файдалану турында карар кабул итү зарурлыгын һәм (яки) максатчанлыгын нигезләү;

3) балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм аларны сәламәтләндерүне, аларга медицина ярдәме күрсәтүне, балаларда авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклауны һәм социаль хезмәт күрсәтүне тиешенчә тәэмин итү мөмкинлеген оешмага беркетелгән балалар өчен тиешле социаль инфраструктура объектыннан файдаланганнан соң нигезләү;

4) балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм аларны сәламәтләндерүне, аларга медицина ярдәме күрсәтүне, балаларда авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклауны һәм социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү буенча балигъ булмаганнарның законнарда билгеләнгән хокукларын үтәү өчен күрү мөмкин булган һәм (яки) күздә тотылган чаралар турында тәкъдимнәр.

9. Әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

1) балалар өчен социаль инфраструктура объектына хокук билгели торган документларның күчермәләре;

2) балалар өчен социаль инфраструктура объектын оешмага оператив идарә хокукында беркетүне, аренда шартнамәсе буенча вакытлыча файдалануга, түләүсез файдалануга тапшыруны раслаучы документларның күчермәләре (булган очракта);

3) балалар өчен социаль инфраструктура объектының техник торышы, оешманың матди-техник базасының торышы, шул исәптән оператив идарә хокукында оешмага беркетелгән мөлкәт турында мәгълүматларны үз эченә алган документларның күчермәләре (булган очракта);

4) балалар өчен социаль инфраструктура объектыннан файдалану турында тиешле карар кабул итү зарурлыгын һәм максатчанлыгын раслаучы документлар (булган очракта);

5) җир участогына хокук билгели торган документларның күчермәләре (булган очракта).

Әлеге Нигезләмә таләпләрен исәпкә алып, документлар кәгазь төрдә оешма тарафыннан Башкарма комитетка яки тармак идарәсе тарафыннан комиссиягә тапшырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән, дәүләт органнары, ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган кирәкле документлар оешма тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган очракта, Башкарма комитет исеменнән җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе күрсәтелгән документларны соратып ала.

10. Әлеге Нигезләмәнең 8 һәм 9 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән гариза һәм документлар, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, кергән көннән башлап өч эш көне эчендә, Башкарма комитет яки тармак идарәсе тарафыннан оешмага кире кайтарылырга тиеш. Әлеге Нигезләмәнең 8 һәм 9 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган гариза һәм документлар, оешмадан комиссиягә кергән көннән башлап өч эш көне эчендә, Башкарма комитет тарафыннан җибәрелә.

Гаризаны һәм документларны кире кайтару сәбәбе булып торган кимчелекләрне бетергәннән соң, оешма вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы яки вәкаләтле орган эксперт бәяләвен үткәрү турында гариза белән кабат комиссиягә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

11. Комиссия эше йомгаклары буенча, комиссиянең утырышта катнашучы әгъзалары тарафыннан имзалана торган тиешле бәяләмә (уңай яки тискәре) рәсмиләштерелә.

Комиссиянең кабул ителгән карар белән килешмәгән әгъзасы, комиссия бәяләмәсенә теркәлә торган аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

Күрсәтелгән бәяләмә, комиссия утырышы үткәрелгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, комиссия тарафыннан әзерләнә һәм рәсмиләштерелә.

12. Муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аларга беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү турында бәяләмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) реконструкцияләүгә, модернизацияләүгә, билгеләнешен үзгәртүгә яки аны бетерүгә, шулай ук арендага, түләүсез файдалануга тапшыруга тәкъдим ителгән муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объекты әйбергә тиешле иялек хокукында беркетелгән оешманың исеме;

2) реконструкцияләүгә, модернизацияләүгә, билгеләнешен үзгәртүгә яки аны бетерүгә, шулай ук арендага, түләүсез файдалануга тапшыруга тәкъдим ителүче муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектының исеме;

3) Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объекты белән алга таба эш итү турында комиссия утырышына чыгарылган тәкъдиме;

4) алар нигезендә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләнешен үзгәртү яки аны бетерү нәтиҗәләре, оешма тарафыннан үзенә беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү нәтиҗәләре, шулай ук муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләре бәяләнә торган Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән барлык критерийларның күрсәткечләре;

5) комиссия карары.

13. Балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү турында бәяләмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) үзгәртеп оештыруга яки бетерүгә тәкъдим ителә торган оешма исеме;

2) Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында комиссия утырышына чыгарылган тәкъдиме;

3) алар нигезендә оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү нәтиҗәләре бәяләнә торган Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән барлык критерийларның күрсәткечләре;

4) комиссия карары.

14. Комиссиянең әлеге Нигезләмәнең 5 пунктындагы 2 һәм 4 пунктчаларында каралган бәяләмәләре, Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары таләпләрен исәпкә алып, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.

Муниципаль милек булып торган һәм муниципаль казна милкен тәшкил иткән балалар өчен социаль инфраструктура объектына карата бәяләмә «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.

15. Үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән критерий күрсәткечләренең берсенә генә булса да ирешелмәгән очракта, комиссия тискәре бәяләмә (муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү яки аны бетерү турында, оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына

аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү мөмкинлеге булмау турында) бирә.

Үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән критерий күрсәткечләренең берсенә генә булса да ирешелмәгән очракта, комиссия тискәре бәяләмә (оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү мөмкинлеге булмау турында) бирә.

16. Үткәрелгән анализ йомгаклары буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән критерий күрсәткечләренең барысына да ирешелгән очракта, комиссия уңай бәяләмә (муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, билгеләнешен үзгәртү яки аны бетерү турында, оешма тарафыннан аңа беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү мөмкинлеге булу турында) бирә.

Үткәрелгән анализ йомгаклары буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән критерий күрсәткечләренең барысына да ирешелгән очракта, комиссия уңай бәяләмә (балалар өчен социаль инфраструктура объектын барлыкка китерә торган оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү мөмкинлеге булу турында) бирә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева